# ЧИШМӘ БАШЫ

**Хәсәншәех балалар бакчасы, октябрь, 2025**







- 16 нчы октябрьдә бакча мөдиребез Ахмадуллина Гүзәл Сәйдәш кызы Арча радиосында кунакта булды. “ Тәрбия көзгесе” дип исемләнгән тапшыруда бакчабызның бүгенгесе, уңышлары һәм милли тәрбия турында сөйләде. “Безнең изге бурычыбыз – булдыра алганча, төрле юнәлештә, төрле чаралар белән тәрбияләү, күрсәтү, төшендерү, үрнәк бирү, ышандыру, аңына сеңдерү хәм әхлаклы, зыялы, сәләтле буын тәрбияләү.Һәр яктан үсеш алган киләчәк буын кешесе үссен дисәк, барлык тәрбия өлкәләрен дә кулланып, тәрбиягә нигез балалар бакчасындагы нәниләргә юнәлдерелергә тиеш. Милли тәрбия бирү, халык тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган теленә, халкына карата соклану, горурлану хисе тәрбияләү, балаларда ул яшәгән республика,авыл, шәһәр тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана. Безнең балалар бакчасында милли хис тәрбияләү түбәндәге юнәлешләрдән чыгып оештырыла:
- -балаларга республика, туган як турында мәгълүмат бирү;
- -халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;
- -әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында кузаллау булдыру;
- -туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;
- -төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу;
- -милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу;
- -халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе барлыгын җиткерү”.

# Бездә күңелле




Мәгариф өлкәсендәге күпьеллык намуслы хезмәте өчен тәрбиячебез вәлиева Рәмлә Камил кызы Арча муниципаль башлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде. Котлыйбыз!



1 нче октябрь – Өлкәннәр көне уңаеннан, бакчабызда эшләп , лаеклы ялга чыккан апаларыбызны, әбиләребезне кунакка чакырдык.



Мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар татар телен өйрәнү буенча олимпиада биремнәрен эшләделәр. Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып, соңгы сулышына кадәр, тел һәм сүз – кешенең аерылгысыз юлдашы. Безнең туган телебез – татар теле, зур тарихлы, бай, җырлы, моңлы тел ул. Туган телебезне тиешенчә белик, өйрәник һәм саклвйк!



16 нчы октябрь – икмәк көне билгеләп үтелде. Икмәк-барлык ризыктан да өстен. Бу гаилә учагының җылысы, уртак табынның шатлыгы һәм буыннар хәтере. Бу турыда искә алу һәм тормышыбызны уңайлырак һәм туклыклырак иткән кешеләргә рәхмәт әйтү өчен үзенчәлекле көн!

# Җиләк -җимешләр темасына шөгыль .

Максат. Балаларның җиләк – җимешләр турында белемнәрен баету, агачларын тану. Фикерләү сәләтен үстерү. Үзләштергән алымнарны кулланып, натурадан карап, күз алдына китереп, предметларны әвәләп ясау.

Шөгыль   барышы: Тәрбияче балаларны  җиләк -җимеш бакчасыны чакыра. Табышмаклар әйтеп, таныштыра.

Алма дисәң алалар ,нәрсә соң ул балалар?

Кып-кызыл кечкенә, эчендэ төш кенә....

Үләннәр арасында яшерендем, ашыйсың килсә ал мине өзеп..

(алма,чия,җиләк)

Балалар,табышмакларның җавапларын  беләсәз икән, рәхмәт.

Без  аларны бер сүз белән ничек әйтәбез? Җимеш агачлары кайда үсә?

Хәзер бездә нинди ел фасылы әле?  (балалар җаваплары)

Әйе. Хәзер көз көне өлгергән алмаларны җыеп алыйк әле. (Уен. Кәрзиннәргә таралган алмаларны тутыралар.)

Балалар әйдәгез пластилиннан алмалар әвәләп  тә алыйк әле. Кем нинди алма ярата? (Кызыл сары яшел баллы .) Бергәләп әвәләп ясыйлар.

Шөгыль  азагында мактау,  бергәләп әвәләгән алмаларны карау.

- Балалар без барыбыз да алма яратабыз икән .Алмагач та сөенде матур алмаларны күреп, булдырдыгыз.





# Әти-әниләр өчен

**Көндәлек режимның әһәмияте .**

**Бала балалар бакчасына йөри башлау белән көйсезләнә,еш авырый башлый. Моның сәбәбе нидә икән ? Моның беренче сәбәбе булып әти -әнинең баланы көндәлек режимга өйрәтмәве тора. Бала сау -сәләмәт,тыныч һәм акыллы булып үссен өчен, аны билгеле бер режимга өйрәтү мөһим . Саф һавада йөрү һәм баланы вакытында йокларга яткызу кирәк. Мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләрендә көндәлек режим тиешенчә саклана. Балалар бакчасындагы режим өйдә дә үтәлергә тиеш.Таләпләрне төгәл үтәгәндә бала стрессլы хәлләрдән, киеренкелектән азат була. Балаларыбыз сәламәт һәм акыллы булсын.**

